**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

21.09.2022 № 304

**Татарстан Республикасы Президентының «Аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан алынган бүләкләрне кабул итү, саклау, аларның бәясен билгеләү, шулай ук әлеге бүләкләрне сату (түләп алу) тәртибе турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан алынган бүләкләрне кабул итү, саклау, аларның бәясен билгеләү, шулай ук әлеге бүләкләрне сату (түләп алу) тәртибе турында» 2015 елның 24 июнендәге 389 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 26 августындагы 502 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан алынган бүләкләрне кабул итү, саклау, аларның бәясен билгеләү, әлеге бүләкләрне сатуны (түләп алуны) оештыру, шулай ук кыйммәтле металлар һәм (яисә) асылташлардан эшләнгән бүләкне сатып алу турында гариза бирелмәгән очракта, әлеге бүләкне Россия Федерациясе Кыйммәтле металлар һәм асылташлар дәүләт фондына бирү өчен «Россия Федерациясе Финанс министрлыгы каршындагы Россия Федерациясенең кыйммәтле металлар һәм асылташлар дәүләт фондын формалаштыру, кыйммәтле металларны һәм асылташларны саклау, тапшыру һәм файдалану буенча дәүләт учреждениесе (Россия Гохран)» федераль казна учреждениесенә тапшыру вәкаләтләрен бирергә.»;

б) аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан

алынган бүләкләрне кабул итү, саклау, аларның бәясен билгеләү, шулай ук әлеге бүләкләрне сату (түләп алу) тәртибе турында нигезләмәдә:

12 пунктның беренче җөмләсендә «гаризаның» сүзен «бүләкне сатып алу турында гаризаның» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктта «әлеге Нигезләмәнең 11 пунктында» сүзләреннән соң «кыйммәтле металлардан һәм (яисә) асылташлардан эшләнгән бүләктән тыш,» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $14^1$ пункт өстәргә:

«$14^1$. Кыйммәтле металлардан һәм (яисә) асылташлардан эшләнгән бүләкне сатып алу турында гариза бирелмәгән очракта, мондый бүләк Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе Кыйммәтле металлар һәм асылташлар дәүләт фондына бирү өчен «Россия Федерациясе Финанс министрлыгы каршындагы Россия Федерациясенең кыйммәтле металлар һәм асылташлар дәүләт фондын формалаштыру, кыйммәтле металларны һәм асылташларны саклау, тапшыру һәм файдалану буенча дәүләт учреждениесе (Россия Гохран)» федераль казна учреждениесенә тапшырылырга тиеш.»;

19 пунктта «үзләренең вазыйфа биләүләре яисә хезмәт вазыйфаларын башкаруларына бәйле рәвештә» сүзләрен «аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге боерык аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**